ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.10. 2020 ел Баулы шәһәре № 208

2021 елга Баулы муниципаль районының балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” карары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2021 елга расларга:

кушымтадагы Баулы муниципаль районының балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын;

Баулы муниципаль районының балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булган чоры дәвамында балаларга өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карар ул рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан бурлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 30 октябрендәге
207 номерлы карарына
кушымта

2021 елга Баулы муниципаль районының балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елына сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Укытуның беренче елы | Укытуның икенче елы | Укытуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җире | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җире | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җире | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җире | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җире | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җире | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Эколого-биологик | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |